**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

_15.03.2022_ ___192-п___

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын, шул исәптән вакытыннан алда, туктату, файдалану хокукын гамәлгә ашыруны туктатып тору һәм файдалану хокукын чикләү тәртибен раслау турында

«Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законы, «Татарстан Республикасы территориясендә җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2022 елның 25 февралендәге 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 325 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы турындагы нигезләмә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 4 ноябрендәге 917 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану тәртибе нигезендә боерык бирәм:

1. Кушымтада бирелгәннәрне расларга:

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын, шул исәптән вакытыннан алда, туктату, файдалану хокукын гамәлгә ашыруны туктатып тору һәм файдалану хокукын чикләү тәртибен;

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын, файдалану хокукын гамәлгә ашыруны туктатып тору һәм файдалану хокукын чикләү буенча комиссия составын.

2. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын

вакытыннан алда туктату, туктатып тору яки чикләү турында карарлар кабул итү тәртибен раслау турында» 2021 елның 22 июлендәге 799-п номерлы боерыгын көчен югалткан дип танырга.

3. Хокукый тәэмин итү бүлеге әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәве өчен җибәрергә.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары И.И.Гобәдуллинга йөкләргә.

Министр А.В. Шадриков

Татарстан Республикасы Экология
һәм табигать ресурслары
министрлыгының 2022 елның 15
мартындагы 192-п номерлы
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын, шул исәптән вакытыннан алда, туктату, файдалану хокукын гамәлгә ашыруны туктатып тору һәм файдалану хокукын чикләү тәртибе

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын, шул исәптән вакытыннан алда, туктату, файдалану хокукын гамәлгә ашыруны туктатып тору һәм файдалану хокукын чикләү буенча әлеге Тәртип (алга таба – Тәртип) «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законы, «Татарстан Республикасы территориясендә җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2022 елның 25 февралендәге 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 325 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы турындагы нигезләмә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 4 ноябрендәге 917 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану тәртибе нигезендә эшләнде.

1.2. Татарстан Республикасы территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән (алга таба – җир асты байлыклары кишәрлеге) файдалану хокукы Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы (алга таба – Министрлык) инициативасы буенча Җир асты байлыклары турындагы законның 20, $20^1$ һәм $20^2$ статьяларының икенче өлешендә билгеләнгән очракларда вакытыннан алда туктатылырга, туктатып торылырга яисә чикләнергә мөмкин.

1.3. Җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукы Министрлык тарафыннан түбәндәге очракларда вакытыннан алда туктатылырга мөмкин:

1) җир асты байлыкларыннан файдалану нәтиҗәсендә кешеләр гомеренә яки сәламәтлегенә турыдан-туры янау барлыкка килгәндә;

2) җир асты байлыкларыннан файдаланучының җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия шартларын бозуы, мондый лицензия нигезендә аларны бер

тапкыр үтәмәү җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктату өчен нигез булып тора;

3) җир асты байлыклары кишәрлегеннән җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия буенча файдалану шартларын системалы (дүрт ел дәвамында ике һәм аннан да күбрәк тапкыр) бозу;

4) әгәр җир асты байлыкларыннан файдаланучы җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиядә билгеләнгән вакыт эчендә җир асты байлыкларыннан файдалануны гамәлгә ашыруга керешмәгән булса;

5) җир асты байлыкларыннан файдаланучы затның бетерелүе;

6) җир асты байлыкларыннан файдаланучының җир асты байлыкларыннан нәтиҗәле файдалану һәм аларны саклау буенча Җир асты байлыклары турындагы законның 23 статьясының беренче өлешендә билгеләнгән таләпләрне бозуы;

7) Җир асты байлыклары турындагы законның 27 статьясы нигезендә җир асты байлыкларыннан файдаланучының җир асты байлыкларыннан файдалануы турында җир асты байлыклары турында геологик мәгълүматны геологик мәгълүматның федераль фондына һәм аның территориаль фондларына, шулай ук Министрлыкның геологик мәгълүмат фондына тапшырмавы һәм (яки) аны бирү тәртибен бозуы;

8) җир асты байлыкларыннан файдаланучының җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктату турында гариза бирүе;

9) концессия килешүләре турындагы Россия Федерациясе законнарында, дәүләт-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык турында Россия Федерациясе законнарында каралган шартларның барлыкка килүе;

10) Җир асты байлыклары турындагы законның $2^1$ статьясының бишенче өлеше нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан карар кабул ителгән очракта.

1.4. Җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын гамәлгә ашыру түбәндәге очракларда туктатып торылырга мөмкин:

1) җир асты байлыклары кишәрлегендә җир асты байлыкларыннан файдалануны вакытлыча туктатудан башка бетерү мөмкин булмаган җир асты байлыкларыннан файдалану нәтиҗәсендә кешеләр тормышына яисә сәламәтлегенә турыдан-туры янау барлыкка килгән очракта;

2) табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү, шулай ук тулаем алганда җир асты байлыклары кишәрлегендә хәрби гамәлләр алып барылган очракта;

3) җир асты байлыкларыннан файдаланучының җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиядә каралган җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын Җир асты байлыклары турындагы законның $23^2$ һәм (яки) $36^1$ статьяларында каралган проект документларыннан башка гамәлгә ашыруы очрагында;

4) җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итүнең федераль органы билгеләгән очракларда, җир асты байлыкларыннан файдаланучы тарафыннан җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын гамәлгә ашыруны туктатып тору турында гариза бирелгән очракта;

5) җир асты байлыкларыннан файдаланучының җир асты байлыкларыннан нәтиҗәле файдалану һәм аларны саклау буенча Җир асты байлыклары турындагы законның 23 статьясының беренче өлешендә билгеләнгән таләпләрне бозуы.

1.5. Җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукы түбәндәге очракларда чикләнергә мөмкин:

1) җир асты байлыкларыннан файдалануны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә кешеләрнең гомере яки сәламәтлеге өчен турыдан-туры куркыныч барлыкка килеп, аны җир асты байлыклары кишәрлегенең бер өлешендә Җир асты байлыклары турындагы законның $23^2$ һәм (яки) $36^1$ статьяларында каралган проект документларында күрсәтелгән эшләрнең аерым төрләрен уздыруны вакытлыча туктатып тормыйча бетереп булмаган очракта;

2) табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килгәндә, шулай ук файдалануга бирелгән җир асты байлыклары кишәрлегенең бер өлешендә хәрби гамәлләр алып барылган очракта;

3) җир асты байлыкларыннан файдаланучы тарафыннан файдалануга бирелгән җир асты байлыклары кишәрлегенең бер өлешеннән файдалануны билгеләнгән тәртиптә расланмаган Җир асты байлыклары турындагы законның $23^2$ һәм (яки) $36^1$ статьяларында каралган проект документларыннан башка гамәлгә ашырылган очракта;

4) Җир асты байлыклары турында законның 8 статьясында каралган нигезләр булуы;

5) җир асты байлыкларыннан файдаланучының җир асты байлыкларыннан нәтиҗәле файдалану һәм аларны саклау буенча Җир асты байлыклары турындагы законның 23 статьясының беренче өлешендә билгеләнгән таләпләрне бозуы.

1.6. Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктату, җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын гамәлгә ашыруны туктатып тору яки җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын чикләү процедурасын башлау өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) Татарстан Республикасы территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын вакытыннан алда туктату, туктатып тору яисә чикләү турында карарлар кабул итү нигезен үз эченә алган, үзенә йөкләнгән вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда Министрлык тарафыннан алынган яисә дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар, гражданнар тарафыннан бирелгән, шулай ук башка чыганаклардан алынган мәгълүмат, мондый мәгълүматның дөреслегенә карата тикшерү уздырылганнан соң;

2) җир асты байлыкларыннан файдаланучының җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктатуы яки җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын гамәлгә ашыруны туктатып торуы турындагы гаризасы;

3) юридик зат – җир асты байлыкларыннан файдаланучыны бетерү турында Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан Интернет-сервисны кулланып алынган, Федераль салым хезмәтенең рәсми сайтында урнаштырылган мәгълүмат;

4) физик зат – җир асты байлыкларыннан файдаланучының шәхси эшкуар сыйфатында эшчәнлеген туктатуы турында Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт

реестрыннан Интернет-сервисны кулланып алынган, Федераль салым хезмәтенең рәсми сайтында урнаштырылган мәгълүмат.

1.7. Җир асты байлыкларыннан файдаланучының җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктатуы яки җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын гамәлгә ашыруны туктатып торуы турындагы гаризасында түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) җир асты байлыкларыннан файдаланучы турында белешмәләр, шул исәптән юридик зат өчен – тулы исеме, аның оешу-хокук формасы, электрон почта адресы (булган очракта), почта адресы, төп дәүләт теркәү номеры, салым түләүченең тәңгәллек номеры, шәхси эшкуар өчен – фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), электрон почта адресы (булган очракта), шәхси эшкуарның төп дәүләт теркәү номеры, салым түләүченең тәңгәллек номеры, ә чит ил заты өчен – тиешле чит ил дәүләте законнары нигезендә салым түләүченең тиешле тәңгәллек номеры;

2) җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиянең дәүләт теркәү номеры һәм аны дәүләт теркәвенә алу көне;

3) җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктату мизгеле (җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктату турында гариза биргән очракта) яисә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын гамәлгә ашыруны туктатып тору вакыты (җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын гамәлгә ашыруны туктатып тору турында гариза биргән очракта);

4) җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктату яисә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын гамәлгә ашыруны туктатып тору сәбәпләре;

5) җир асты байлыкларыннан файдаланучының җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия буенча файдалану шартларын үтәве турында мәгълүмат;

6) тау эшкәртүләрне, бораулау скважиналарын һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле башка корылмаларны (җир асты байлыклары кишәрлегендә тау эшкәртүләр, бораулар скважиналары һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле башка корылмалар булган очракта) консервацияләү һәм бетерүнең техник проектын Җир асты байлыклары турындагы законның $23^2$ статьясында каралган тәртиптә килештерү турында карар белешмәләре;

7) файдалы казылма запасларына һәм җир асты суларына дәүләт экспертизасы бәяләмәсенең, Җир асты байлыклары турындагы законның 29 статьясында каралган файдалануга бирелә торган җир асты байлыклары кишәрлекләре турындагы геологик мәгълүматның белешмәләре яисә Җир астый байлыклары турындагы законның 26 статьясы нигезендә имзаланган тау эшкәртүләрне, бораулау скважиналарын һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле башка корылмаларны бетерү яки консервацияләү турында акт белешмәләре (Тәртипнең 1.4 пунктының 4 пунктчасында каралган нигездә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын гамәлгә ашыруны туктатып тору турында гариза тапшырылган очракта).

Гаризага җир асты байлыкларыннан файдаланучы – юридик зат исеменнән гамәлләр башкаруга затның вәкаләтләрен раслаучы документ теркәлергә тиеш (мондый физик зат җир асты байлыкларыннан файдаланучы зат исеменнән ышанычнамәдән башка гамәл кылу хокукына ия булуга нигез булган физик затны билгеләү турында яисә сайлап алу турында карар яки боерык күчермәсе) (алга таба – җир асты байлыкларыннан файдаланучы затның җитәкчесе). Әгәр җир асты байлыкларыннан файдаланучы исеменнән башка зат эш итсә, гаризада шулай ук җир асты байлыкларыннан файдаланучы зат исеменнән (булган очракта) һәм җир асты байлыкларыннан файдаланучы затның җитәкчесе (юридик зат өчен) яки җир асты байлыкларыннан файдаланучының башка вәкаләтле җитәкчесе тарафыннан имзаланган гамәлләр башкаруга ышанычнамәнең төп нөсхәсе булырга тиеш. Күрсәтелгән ышанычнамә җир асты байлыкларыннан файдаланучының вәкаләтле җитәкчесе тарафыннан имзаланган очракта, гаризада шулай ук мондый затның вәкаләтләрен раслаучы документ та булырга тиеш.

1.8. Гариза һәм аңа теркәп тапшырыла торган документлар һәм Тәртипнең 1.7 пунктында күрсәтелгән белешмәләр Министрлыкка тапшырыла.

1.9. Җир асты байлыклары турындагы законның 21 статьясындагы икенче өлеше нигезендә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктату турындагы гариза җир асты байлыкларыннан файдаланучы тарафыннан җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктату өчен соралган датага кадәр алты айдан да соңга калмыйча бирелергә тиеш.

1.10. Алынган гариза Министрлык тарафыннан кергән көнендә теркәлә. Гаризаны теркәгәндә аңа теркәү номеры бирелә, шулай ук аның алынган көне күрсәтелә.

Министрлык гаризаны теркәгән көннән соң биш эш көненнән дә артмаган вакыт эчендә гариза составында Тәртипнең 1.7 пунктында каралган документларның һәм белешмәләрнең булуын, шулай ук гариза бирүнең Тәртипнең 1.9 пунктында каралган вакыты саклануын тикшерә.

Бирелгән гариза составында Тәртипнең 1.7 пунктында каралган документлар һәм белешмәләр булмаган очракта һәм (яки) гаризаны Тәртипнең 1.9 пунктында каралган чорны бозып тапшырган очракта, гариза Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын, файдалану хокукын гамәлгә ашыруны туктатып тору һәм файдалану хокукын чикләү буенча комиссия тарафыннан карау өчен җибәрелергә тиеш түгел, бу хакта Министрлык гаризада күрсәтелгән электрон почта адресы (булган очракта) буенча яисә гаризада күрсәтелгән почта адресы буенча мөрәҗәгать итүчегә гаризаны теркәгән көннән башлап биш эш көненнән артмаган чорда хәбәр итә.

## 2. Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын, файдалану хокукын гамәлгә ашыруны туктатып тору һәм файдалану хокукын чикләү буенча комиссия

2.1. Татарстан Республикасы территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын вакытыннан алда туктату, туктатып тору яки чикләүгә бәйле мәгълүматны объектив, сыйфатлы һәм комплекслы анализлау максатларында Министрлыкта даими эшләүче орган – Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын, файдалану хокукын гамәлгә ашыруны туктатып тору һәм файдалану хокукын чикләү буенча комиссия (алга таба – Комиссия) оештырыла.

2.2. Комиссия утырышлары әлеге Тәртипнең 1.6 пункты нигезендә Министрлыкка алынган мәгълүмат Татарстан Республикасы территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын вакытыннан алда туктату, туктатып тору һәм чикләү өчен нигез булып торган очракта һәр конкрет җир кишәрлегенә карата уздырыла.

2.3. Комиссия рәисе, рәис урынбасары, сәркатип һәм комиссия әгъзаларыннан тора. Комиссия составы Министрлыкның штат хезмәткәрләреннән төзелә. Комиссия әгъзаларының саны 10 кеше булырга тиеш.

2.4. Комиссия утырышын рәис, ә ул булмый торган чорда – комиссия рәисе урынбасары үткәрә.

2.5. Комиссия тәкъдим итү рәвешендәге карарлар (алга таба – карарлар) кабул итә. Комиссия утырышы, әгәр анда комиссия әгъзаларының кимендә 50% катнашса, хокуклы була. Карар өчен өчен утырышта катнашкан Комиссия әгъзаларының 50% артык өлеше тавыш бирсә, ул кабул ителгән дип санала. Тавышлар тигез булса, Комиссия утырышында рәислек итүче зат тавышы хәлиткеч булып тора.

2.6. Комиссия карары ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә һәм Комиссия утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә. Беркетмә Комиссия утырышы узган көннән соң биш эш көне эчендә рәсмиләштерелә һәм утырышта катнашкан барлык Комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана. Комиссия әгъзалары беркетмәгә Комиссия утырышында каралган мәсьәләләр буенча язмача рәсмиләштерелгән аерым фикерне теркәп куярга хокуклы.

## 3. Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктату, туктатып тору яки чикләү турындагы мәсьәләне Министрлык тарафыннан карау нәтиҗәләре буенча кабул ителә торган карарлар

3.1. Комиссия утырышларында җирле әһәмияттәге җир асты байлыкларының конкрет кишәрлегенә карата түбәндәгечә карарлар кабул ителә:

1) әлеге Тәртипнең 1.3 пунктының 2-4, 6 һәм 7 пунктчаларында каралган очракларда, җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдаланучы адресына җир асты байлыкларыннан файдаланучы җибәргән җитешсезлекләр һәм җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктату ихтималлыгы турында белдерү җибәрү хакында;

2) әлеге Тәртипнең 1.4 пунктында каралган очракларда, җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын туктатып тору турында;

3) әлеге Тәртипнең 1.5 пунктында каралган очракларда, җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын чикләү турында;

4) әлеге Тәртипнең 1.3 пунктчасының 1, 5, 8-10 пунктчаларында каралган очракларда, җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалануны вакытыннан алда туктату турында;

5) әлеге Тәртипнең 1.3 пунктындагы 2-4, 6 һәм 7 пунктчаларында каралган очракларда, җир асты байлыкларыннан файдаланучының рөхсәт ителгән хокук бозулар турында хәбәрдә күрсәтелгән җитешсезлекләрне бетерү фактын билгеләгәндә җир асты байлыкларыннан файдалануны вакытыннан алда туктату турында;

6) җир асты байлыкларыннан файдаланучының гаризасы буенча җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктату яисә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын гамәлгә ашыруны туктатып тору турында;

7) җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын чикләү, туктатып тору яки вакытыннан алда туктату өчен нигезләр булмавы турында.

3.2. Комиссия тарафыннан җир асты байлыкларыннан файдаланучы адресына җир асты байлыкларыннан файдаланучы җибәргән бозулар һәм җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктату ихтималлыгы турында белдерү җибәрү хакында карар кабул ителгән очракта, Министрлыкның җир асты байлыкларыннан файдалануны җайга салу бүлеге белгече Комиссия утырышы беркетмәсен алганнан соң ун эш көне эчендә җир асты байлыкларыннан файдаланучы җибәргән җитешсезлекләр һәм җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктату ихтималлыгы турында белдерү проекты рәсмиләштерә һәм имзалау өчен Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министрына (алга таба – министр) җибәрә, анда түбәндәгеләр була:

1) Тәртипнең 1.3 пунктында күрсәтелгән, түбәндәге бер яисә берничә шартны Комиссия тарафыннан билгеләүгә күрсәтү:

- җир асты байлыкларыннан файдаланучының җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия шартларын бозуы, мондый лицензия нигезендә аларны бер тапкыр үтәмәү җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктату өчен нигез булып тора;

- җир асты байлыклары кишәрлегеннән җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия буенча файдалану шартларын системалы (дүрт ел дәвамында ике һәм аннан да күбрәк тапкыр) бозу;

- әгәр җир асты байлыкларыннан файдаланучы җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиядә билгеләнгән вакыт эчендә җир асты байлыкларыннан файдалануны гамәлгә ашыруга керешмәгән булса;

- Җир асты байлыклары турындагы законның 27 статьясы нигезендә җир асты байлыкларыннан файдаланучының җир асты байлыкларыннан файдалануы турында җир асты байлыклары турында геологик мәгълүматны геологик мәгълүматның федераль фондына һәм аның территориаль фондларына, шулай ук Министрлыкның геологик мәгълүмат фондына тапшырмавы һәм (яки) аны бирү тәртибен бозуы.

2) җитешсезлекләрне бетерү турында мәгълүмат бирү турында таләп һәм аны бирү вакыты;

3) әлеге җитешсезлекләр белдерүдә күрсәтелгән чорда бетерелмәгән очракта, җир асты байлыкларыннан файдалану хокукының вакытыннан алда туктатылырга мөмкин булуы турында кисәтү.

Белдерүдә билгеләнә торган җитешсезлекләрне бетерү чоры өч һәм унике айдан да ким түгел һәм җир асты байлыкларыннан файдаланучыга яисә аның вәкиленә җитешсезлекләр турында язма хәбәр җиткерелгән көннән башлап исәпләнә. Белдерү, әгәр ул җибәрелгән затка килеп ирешсә, ләкин бу затка бәйле хәлләр нәтиҗәсендә аңа тапшырылмаган булса яисә җир асты байлыкларыннан файдаланучыга яки аның вәкиле аның белән танышып чыкмаган очракларда да, җиткерелгән булып санала.

3.3. Министр җир асты байлыкларыннан файдаланучы җибәргән җитешсезлекләр һәм җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктату ихтималлыгы турындагы белдерүне җир асты байлыкларыннан файдаланучы җибәргән җитешсезлекләр һәм җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктату ихтималлыгы турында белдерү проекты имзалау өчен алынган вакыттан башлап ун эш көне эчендә имзалый.

3.4. Министрлыкның җир асты байлыкларыннан файдалануны җайга салу бүлеге белгече җир асты байлыкларыннан файдаланучы җибәргән җитешсезлекләр һәм җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктату ихтималлыгы турында белдерү имзаланганнан соң өч эш көне эчендә җир асты байлыкларыннан файдаланучыга тиешле белдерү кәгазенең күчермәсен заказлы хат белән җибәрә.

3.5. Комиссия җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктату яисә чикләү турында карар кабул иткән очракта, Министрлыкның җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү бүлеге белгече, Комиссия утырышы беркетмәсе алынганнан соң ун эш көне эчендә, җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатып тору яки чикләү турында боерык проектын рәсмиләштерә һәм имзалау өчен министрга җибәрә, анда түбәндәгеләр була:

1) Тәртипнең 1.4 һәм 1.5 пунктларында күрсәтелгән шартлар нигезендә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатып тору яисә чикләү нигезе;

2) җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын туктатуга яисә чикләүгә китергән сәбәпләрне бетерү өчен җир асты байлыкларыннан файдаланучы үткәрергә тиешле чаралар, аларны үткәрү тәртибе һәм чорлары;

3) мондый тыюның сәбәпләрен күрсәтеп, үткәрелүе тыела торган эш төрләре (җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы чикләнгән очракта);

4) җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатып тору яисә чикләү турында карар кабул ителгән карар юкка чыгарылырга мөмкин булган шартлар;

5) Татарстан Республикасының геологик мәгълүмат фондына тиешле йөкләмәләр.

3.6. Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатып тору яки чикләү турындагы боерыкны министр җир асты байлыкларының конкрет кишәрлегенә карата җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатып тору

яки чикләү турындагы боерык проектына кул куйганнан соң ун эш көне эчендә имзалый.

3.7. Министрлыкның җир асты байлыкларыннан файдалануны җайга салу бүлеге белгече җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатып тору яки чикләү турында боерык проекты имзаланганнан соң өч эш көне эчендә кулга тапшыру турында белдереп, җир асты байлыкларыннан файдаланучыга тиешле боерык күчермәсен заказлы хат белән юллый.

3.8. Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын туктатып тору яки чикләү турындагы карар җир асты байлыкларыннан файдаланучыга лицензия шартларын бозуларны бетерү өчен каршылык булып тормый.

3.9. Җитешсезлекләрне бетерү өчен белдерүдә күрсәтелгән срок узгач, Комиссия җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктату, туктатып тору яки чикләү буенча ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү фактын билгеләү яки аларның бетерелмәвен, шулай ук ачыкланган җитешсезлекләрне белдерүдә билгеләнгән срокта бетерү мөмкинлеген бирмәгән объектив шартларны билгеләү предметыннан гыйбарәт булган материалларны яңадан карап тикшерә.

3.10. Әлеге Тәртипнең 1.3 пунктындагы 1, 5, 8-10 пунктчаларында каралган очракларда һәм җир асты байлыкларыннан файдаланучы җибәрелгән җитешсезлекләр турындагы белдерүдә күрсәтелгән бозуларны анда күрсәтелгән срокта бетермәгән очракта һәм Комиссия җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктату кирәклеге турында карар кабул итсә, Министрлыкның җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү бүлеге белгече Комиссия утырышы беркетмәсе алынган вакыттан башлап ун эш көне эчендә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктату турында Министрлык боерыгын рәсмиләштерә һәм имзалау өчен министрга җибәрә, анда түбәндәгеләр була:

1) Җир асты байлыкларыннан файдалану турындагы законның 20 статьясы нигезендә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктату турында карар кабул итү нигезләре;

2) файдалы казылмалар чыгару предприятиесен һәм җир асты корылмаларын бетерү һәм консервацияләү буенча җир асты байлыкларыннан файдаланучының файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган чараларны үткәрү зарурлыгына күрсәтү;

3) җир асты байлыкларыннан файдалану хокукының туктатылу датасы;

4) юридик зат турындагы белешмәләрне Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдыру турында белешмәләр яисә шәхси эшкуар турындагы белешмәләрне Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдыру турында белешмәләр (предприятиене яисә хуҗалык эшчәнлегенең башка субъектын бетерүгә бәйле рәвештә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы вакытыннан алда туктатылган очракта);

5) Татарстан Республикасының геологик мәгълүмат фондына тиешле йөкләмә.

3.11. Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктату, туктатып тору яки чикләү турындагы боерык министр тарафыннан җир асты байлыкларының конкрет кишәрлегенә карата вакытыннан алда туктату, туктатып тору яки чикләү турындагы боерык проекты алынганнан соң ун эш көне имзалана.

3.12. Министрлыкның җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү бүлеге белгече җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктату, туктатып тору яки чикләү турындагы боерык имзаланганнан соң өч эш көне эчендә җир асты байлыкларыннан файдаланучыга тиешле боерык күчермәсен, кулга тапшыру турында белдереп, заказлы хат белән җибәрә.

3.13. Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктату турында Министрлык боерыгы чыккан датадан башлап җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукы вакытыннан алда туктатыла, туктатып торыла яки чикләнә.

3.14. Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатып тору яки чикләүгщ китереп чыгарган шартлар бетерелгән очракта, Министрлык җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын яңадан торгызу яки чикләүне юкка чыгару турында боерык чыгара. Куллану хокукы элекке шартларда яки, лицензиягә тиешле үзгәрешләр кертеп, тулы күләмдә торгызыла. Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы туктатылган яисә чикләнгән вакыт, җир асты байлыкларыннан файдаланучының гаебе булмаса, җир асты байлыкларыннан файдаланучының гаризасы буенча җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиянең гомуми вакытына кертелми.

## 4. Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктату, туктатып тору яки чикләү турындагы карарларга шикаять белдерү

4.1. Җир асты байлыкларыннан файдаланучы җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктату, туктатып тору яки чикләү турындагы карары белән килешмәсә, ул аңа закон нигезендә шикаять бирергә мөмкин.

## 5. Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктатканда документлар рәсмиләштерү

5.1. Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы вакытыннан алда туктатылган җир асты байлыкларыннан файдаланучы вәкаләтле органның язма белдерүендә күрсәтелгән вакытта Министрлыкка лицензия тапшырырга тиеш. Тапшырылган лицензиядә лицензияне гамәлдән чыгару турында штамп куела.

5.2. Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктату турындагы карар күчермәсе боерыкны теркәгән көннән башлап биш эш көне эчендә Министрлыкның җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү бүлеге белгече тарафыннан Татарстан Республикасының җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлеге урнашкан территориядәге муниципаль берәмлекнең

җирле үзидарә органнарына, Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең (Ростехнадзор) Идел буе идарәсенә, «Идел буе федераль округы буенча территориаль геологик мәгълүмат фонды» федераль бюджет учреждениесенең Татарстан филиалына һәм Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсенә җибәрә.

5.3. Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктатуга бәйле документлар Министрлыкта 10 ел дәвамында сакланырга тиеш.

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигать
ресурслары министрлыгының
2022 елның 15 мартындагы
192-п номерлы боерыгы белән
расланды

## 2. Татарстан Республикасы территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын вакытыннан алда туктату, туктатып тору һәм чикләү комиссиясенең составы

| | |
|---|---|
| Гобәйдуллин Илнур Ирек улы | Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры урынбасары – җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын, файдалану хокукын гамәлгә ашыруны туктатып тору һәм файдалану хокукын чикләү буенча комиссия рәисе |
| Вахитов Самат Таһир улы | Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министрлыгының җир асты байлыкларыннан файдалану мөнәсәбәтләрен җайга салу идарәсе башлыгы – җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын, файдалану хокукын гамәлгә ашыруны туктатып тору һәм файдалану хокукын чикләү буенча комиссия рәисе урынбасары |
| Лукина Людмила Александровна | Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министрлыгының җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү бүлеге җитәкчесе – җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын, файдалану хокукын гамәлгә ашыруны туктатып тору һәм файдалану хокукын чикләү буенча комиссия сәркатибе |
| Ахманова Татьяна Петровна | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының углеводород чималы геологиясе бүлеге җитәкчесе |
| Полушин Владислав Леонидович | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының мәгълүмат-геология ресурслар һәм геология тирәлеген күзәтү бүлеге җитәкчесе |
| Полюшков Алексей Сергеевич | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының Дәүләт экология |

| | |
|---|---|
| | күзәтчелеге инспекциясе җитәкчесе |
| Ткачук Алексей Иванович | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының хокукый тәэмин итү бүлеге җитәкчесе |
| Чеснокова Ирина Валерьевна | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының җир асты байлыкларыннан файдалануны җайга салу бүлеге җитәкчесе |
| Чинарев Алексей Михайлович | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының минерал-чимал һәм су ресурслары идарәсе җитәкчесе |
| Шутникова Светлана Анатольевна | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының каты файдалы казылмалар геологиясе бүлеге җитәкчесе |